# Муса Җәлил музеена сәяхәт

Балтач гимназиясенең 1нче инженер сыйныфында укучылар Карадуган авылындагы М. Җәлил музеенда экскурсиядә булды. Биредә укучыларга герой-шагыйрьнең тормыш юлы, батырлыгы, шигырьләре турында сөйләделәр, кызыклы экспонатлар белән таныштырдылар. Балалар М.Җәлилнең шигырьләрен яттан сөйләделәр. Шулай ук Себер тракты музее экспонатларын да карадылар. Ахырдан Зарипова Гүзәлия әзерләгән табында тәмле коймаклар, кайнатмалар белән сыйландылар. Бу сәяхәтне оештырган Зарипова Гүзәлиягә, гаиләсенә, музей җитәкчесе Фирая ханым Зыятдиновага, музей хезмәткәрләренә зур рәхмәт.

